**«РАСЛЫЙМ»**

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
__________ Э.Н. Фәттахов
"__6__"__февраль__2015 нче ел

# ТАТАР ТЕЛЕ

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**IX сыйныфында укучыларына 2015 нче елда**
**татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен**
**үрнәк материалларның күрсәтмә варианты**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфында укучыларына 2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен үрнәк материалларның күрсәтмә варианты**

**2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен күрсәтмә материалларга аңлатмалар**

2015 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен күрсәтмә материаллар белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән материаллар тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын да чагылдырмыйлар. 2015 нче елда татар теленнән тест уздыру вакытында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге татар теленнән төп гомуми белем бирү программаларын үзләштергән чыгарылыш сыйныф укучыларына 2015 нче елда бердәм республика тесты уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куйган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант бердәм республика тестын узучыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә тестның структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында гомуми күзаллау бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне үтәүнең бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Бу мәгълүматлар чыгарылыш сыйныф укучыларында бердәм республика тесты узуга әзерлек осталыгын булдырачак.

**Эш үтәү өчен күрсәтмә**

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләренең 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен, татар теленнән үткәрелә торган бердәм республика тестына 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек** 1 биремнән тора. Анда 2 тапкыр **тыңланган** текстның кыскача эчтәлеге (изложение) языла. Ул 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

**Икенче бүлек** укучылар **үзләре укыган** текстка нигезләнеп башкарыла. Ул 9 биремнән тора (2-10 биремнәр).

2 – 3 нче биремнәрнең җавапларын тәкъдим ителгән 4 варианттан бер дөрес җавапны сайлап алырга һәм 1 нче номерлы җавап бланкына бер цифр белән язарга кирәк.

4 – 14 нче биремнәргә җавапларны укучылар мөстәкыйль рәвештә формалаштыралар. Әлеге биремнәргә җаваплар тест эшенең күрсәтелгән урыннарына сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән языла, соңыннан 1 нче номерлы җавап бланкына күчереп языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

**Өченче бүлектәге** биремне укучылар 2 нче бүлектәге эшләрне үтәү өчен укыган текст буенча башкаралар. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән (15.1, 15.2 һәм 15.3) биремнәрнең берсен сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирү кирәк.

Тест биремнәрен үтәгәндә орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне эшләгәндә, караламадан файдаланырга мөмкин, әмма андагы язулар тест эшенә билге куйганда исәпкә алынмый.

Биремнәрне тәкъдим ителгән эзлеклелектә эшләргә киңәш ителә. Җавап бирергә авырсынган бирем очраса, аны калдырып, башкаларын эшли торырга мөмкин. Вакыт кала икән, аларны яңадан уйлап, эшләп карарга мөмкинлек туа.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез.***
***Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

**1** *Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз.*

Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез.

Изложениенең күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш.

Изложениене чиста һәм таныклык итеп языгыз.

## II бүлек

***Текстны укыгыз һәм 2-14 нче биремнәрне үтәгез.***

### Аккош

1) Һәр җирдә тынгысыз гөрләвекләр челтери. 2) Инде су читләре боздан арчылган, ләкин әле яр буйларында, агач һәм куак төпләрендә ап-ак кар ята. 3) Кичләрен, кояш баер алдыннан, кар өсләре алсу төскә керә. 4) Шул чакны күктә – алсу күл өстендә – алсу кошлар төркеме пәйда була... 5) Озын зифа муеннары алга сузылган, кыска кочле аяклары – артка... 6) Алар киң канатларын гаять салмак селтиләр, ерак юллар кичеп, тәмам арыганнар, хәлдән тайганнар. 7) Син аларны кызганып куясың, камышлы күлгә төшеп, бераз ял итүләрен телисең, ләкин алар баш очыннан гына узып китәләр. 8) Хәер, арадан бер пары, иптәшләреннән аерылып, түбәнрәк төшә түгелме соң?.. 9) Димәк, бу күл – шушы пар аккошның туган төбәге! 10) Бу күлгә алар, бары тик алар гына хуҗа, ә башкалар, шуны белеп, китеп баралар икән.

11) Төшеп җитәрәк, аккошлар муеннарын аска бөктеләр, канатларын җилгә каршы җилпи башладылар, аякларын тырпайтып, алга суздылар. 12) Шул рәвешчә, алар су өстенә төшеп утырдылар..

13) Алсу күл өстендә алсу кошлар йөзә... 14) Менә алар икесе ике якка аерылып китәләр дә, кинәт борылып, бер-берсенә каршы килә башлыйлар. 15) Бераздан аккошлар, бөтенләй якынлашып, томшыкка томшык килеп торалалар, гүя исән-имин туган якларына кайту шатлыгын уртаклашалар, үзләренчә тәбрикләшәләр. 16) Ул да булмый, томшыкларын зәңгәр күккә сузып, көмеш быргы авазлары чыгарып кычкырырга тотыналар. 17) Бу – аларның язгы җыры, бу – аларның туй башлап җибәрү турында аваз салулары...

18) Аккош күле... 19) Кайда гына юк андый исемдәге күлләр, ләкин хәзер күбесенең исеме бар, җисеме юк. 20) Аларны әрсез бәндәләр биздергән, шуңа күрә аккошлар безнең якларда бик аз калган. 21) Сез шуны һәрчак истә

тотыгыз: аккошлар – сак кошлар. 22) Алар тынычлыкны яраталар, саф һава, көмештәй саф су яраталар.

*Гарәфи Хәсәновтан*

**Гарәфи Хәсәнов** – *Хәсәнов Гарәфетдин Хәким улы (1921-1992), прозаик, әсәрләрендә туган якның матурлыгына дан җырлый. Ул "Унике матур", "Жирем-суым", "Кошларым-дусларым", "Жир – ул уртак йортыбыз", "Елның дүрт фасылы" исемле повесть һәм хикәя җыентыклары авторы.*

***2 – 10 нчы биремнәрнең җаваплары буларак сүз, сүзтезмә һәм цифр күрсәтелә. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны аерым шакмакка, үрнәктә күрсәтелгәнчә языгыз.***

**2** **Татар сөйләменең үзенчәлеге булган ирен гармониясенә буйсынган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.**

1) Һәр җирдә тынгысыз гөрләвекләр челтери.

2) Бу күлгә алар, бары тик алар гына хуҗа, ә башкалар, шуны белеп, китеп баралар икән.

3) Шул рәвешчә, алар су өстенә төшеп утырдылар..

4) Аларны әрсез бәндәләр биздергән, шуңа күрә аккошлар безнең якларда бик аз калган.

Җавап: ____ .

**3** **Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләне күрсәтегез.**

1) Кичләрен, кояш баер алдыннан, кар өсләре алсу төскә керә.

2) Алар киң канатларын гаять салмак селтиләр, ерак юллар кичеп, тәмам арыганнар, хәлдән тайганнар.

3) Хәер, арадан бер пары, иптәшләреннән аерылып, түбәнрәк төшә түгелме соң?..

4) Алар тынычлыкны яраталар, саф һава, көмештәй саф су яраталар.

Җавап: ____________ .

**4** **4 – 7 нче җөмләләрдән кимлек дәрәҗәсендәге асыл сыйфатны күчереп языгыз.**

Җавап: ______________ .

5 **8 – 11 нче җөмләләрдән чикләүче кисәкчәне табып языгыз.**
Җавап: ______________ .

6 **6 нчы җөмләдән *әкрен* сүзенең синонимын табып языгыз.**
Җавап: ______________ .

7 **13 нче җөмләнең грамматик нигезен күчереп языгыз.**

Җавап: ______________ .

8 **1 – 4 нче җөмләләрдән теркәгечле тезмә кушма җөмләнең номерын языгыз.**
Җавап: ______________ .

9 **Җөмләдә барлык тыныш билгеләре номерланган. *Тезүле бәйләнештәге җөмләләр* арасына куелган номерны языгыз.**
*Син аларны кызганып куясың,[1] камышлы күлгә төшеп,[2] бераз ял итүләрен телисең,[3] ләкин алар баш очыннан гына узып китәләр.[4]*
Җавап: ______________ .

10 **Сөйләмнең тәэсир итү көчен арттыру өчен, 18 – 22 нче җөмләләрнең берсендә *кире сүз тәр*тибе файдаланылган. Шул җөмләнең номерын языгыз.**
Җавап: ______________ .

***Барлык җавапларны, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1, 11.2, 11.3 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**11. 1. Аккош күле... Кайда гына юк андый исемдәге күлләр, ләкин хәзер күбесенең исеме бар, җисеме юк. Аларны әрсез бәндәләр биздергән, шуңа күрә аккошлар безнең якларда бик аз калган,** - җөмләләрендә әйтелгән фикерләрне ничек аңлыйсыз?

Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениене мәкаль яки әйтемнән башлый аласыз. Аны фәнни яки публицистик стильдә язарга мөмкин.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен билге куелмый (ноль балл куела).

**11. 2. Туган илем – туган өем,** - диелә халык мәкалендә. Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Пар аккошлар туган илләренә кайтуны ничек бәйрәм итәләр? ***Туган ил*** төшенчәсенә аңлатма бирегез. **Туган илем – туган өем** темасына сочинение языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениене мәкаль яки әйтемнән башлый аласыз. Аны фәнни яки публицистик стильдә язарга мөмкин.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен билге куелмый (ноль балл куела).

## Татар теленнән бердәм республика тестын бәяләү системасы

### I бүлек

### Тыңлау өчен текст

Кар сулары

Мин кар суына барам. Күгелҗем сукмак буйлап тау арасына менәм. Сукмак тар, аякларны туп-туры басарга кирәк, юкса батасың.

Сукмак читендә кар өсте челтәрләнгән, ул кыш көнендәге кебек күзләрне чагылдырмый, асылташлар сипкәндәй җемелдәми. Кар да картая икән. Дөрес, биредә ул шәһәрдәге кебек каралмаган, пычранмаган, тик тоныкланган, басылган, авырайган. Уйсу җирдә ул әле нык ята, ләкин яз кояшы аны тау түбәсеннән куган инде.

Күптән түгел биредә малай-шалай, чаңгы киеп, таудан тауга очкандыр. Кечкенәләр, чыр-чу килеп, пальто итәкләре катканчы, чана шугандыр. Озакламыйча алар тау араларында, йомшак чирәмдә тәгәрәп уйнар.

Минем кулымда – ак чиләк, эчендә – яшел чүмеч. Без бәләкәй чакларда сыңар чиләк белән суга йөрү юк иде. Хәзер инде мин инемә көянтә асудан күптән биздем, чөнки каладагы квартирабызда су краннан агып тора. Авылда өебез турына колонка куйганнар. Аннан чишмә суы ага. Ул су, җиргә күмелгән торбалар буйлап, тау өстендәге басулар аркылы, еракган агып килә. Ә без чишмәгә шактый озак бара торган идек. Ул су бик кадерле була, аны самавырга гына тоталар иде. (158 сүз)

*Мәдинә Маликовадан*

### Кыска изложение (С1 биремен) тикшерү һәм бәяләү

*1 нче таблица*

| Кыска изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Мин кар суына барам. |
| 2 | Сукмак читендәге кар. |
| 3 | Балалар монда уйнарга килләр. |
| 4 | Краннан су агып торса да, халык чишмә суын эчә. |

*2 нче таблица*

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложение эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма**<br>бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма**<br>бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 0 |
| **ИК2** | **Башлангыч текстны җыйнакландыру** | |
| | Укучы текстның гомуми эчтәлеген бер яки берничә алым белән кыскарткан, җыйнакландырган | 3 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның ике микротемасын җыйнакландырган | 2 |
| | Бер яки берничә алым белән текстның бер микротемасы җыйнакландырылган | 1 |
| | Текстны җыйнакландыру өчен бер алым да **кулланылмаган** | 0 |
| **ИК3** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма**<br>бер логик хата бар<br>**яки**<br>кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма**<br>бердән артык логик хата<br>**яки**<br>кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК1-ИК3 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | 7 |

## II бүлек
## 2 – 10 нчы биремнәрне тикшерү

Икенче бүлектәге һәр биремгә дөрес җавап биргән өчен укучыга **берәр балл** куела. Җавап ялгыш булса яки бөтенләй булмаса, **0 балл** куела. Икенче бүлектәге 9 тест биремենә дөрес җавап биргән өчен укучы җыярга мөмкин булган **иң югары балл – 9**.

*3 нче таблица*

| Биремнәр | Җаваплар |
|---|---|
| 2 | 3 |
| 3 | 2 |
| 4 | алсу |
| 5 | гына |
| 6 | салмак |
| 7 | кошларйөзә |
| 8 | 2 |
| 9 | 3 |
| 10 | 19 |

## III бүлек

### 11 нче биремне тикшерү критерийлары

**11.1 биремнәә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.**

*4 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (11.1) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| $C_1K1$ | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан,<br>**ләкин**<br>аңлатмада 1 хатасы бар. | 1 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган,<br>**яки** | |

| | | |
|---|---|---|
| | имтихан бирүче, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган,<br>**яки**<br>тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **$C_1K2$** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Имтихан бирүче тексттан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Имтихан бирүче тексттан әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче башка тексттан дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Имтихан бирүче әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки**<br>имтихан бирүче биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| **$C_1K3$** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **$C_1K4$** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин**<br>текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| | **$C_1K1$-$C_1K4$ критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | **9** |

Игътибар!

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($C_1$К2-$C_1$К4) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм анық фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (6 нчы таблицаны кара).

**11.2 биременә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.**

*5 нче таблица*

| № | Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (11.1) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| $C_3$К1 | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) аңлатма биргән һәм киңәйтелгән формада тасвирлаган. | 2 |
| | Имтихан бирүче (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) аңлатма биргән,<br>**ләкин**<br>киңәйтелгән формада тасвирламаган. | 1 |
| | Имтихан бирүче ялгыш аңлатма биргән,<br>**яки**<br>төшенчәгә аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| $C_3$К2 | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Имтихан бирүче 2 дәлил-мисал китергән, шуларның берсе укылган тексттан, икенчесе – тормыш тәҗрибәсеннән<br>**яки**<br>Имтихан бирүче 2 дәлил-мисал китергән, шуларның икесе дә укылган тексттан. | 3 |
| | Имтихан бирүче укылган тексттан 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче тормыш тәҗрибәсеннән дәлил-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |
| | Имтихан бирүче бер генә дәлил-мисал да китермәгән. | 0 |
| $C_3$К3 | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүченен эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана, **ләкин** 1 логик хатасы бар, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар, **ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **$C_3K4$** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм тәгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм тәгәлләнгән, **ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| | **$C_3K1$-$C_3K4$ критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | **9** |

Игътибар!

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча ($C_3K2$-$C_3K4$) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик тәгәллеге** аерым бәяләнә (6 нчы таблицаны кара).

*6 нчы таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик тәгәллеген бәяләү критерийлары | |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сойләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| | **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, **изложение һәм сочинениенең күләмен** исәпкә алырга кирәк.

6 нчы таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 100 дән артык сүз булган изложение һәм сочинениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр **изложение һәм сочинениеләрнең** гомуми күләме 50-99 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК – 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела:

ГК – 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр **изложение һәм сочинениеләрнең** гомуми күләме 50 кенә сүз булса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

Әгәр укучы иҗади эшнең бары тик берсен генә (я изложение, я сочинение) үтәсә, ГК1-ГК4 критерийлары буенча бәяләү шулай ук эшнең күләменнән чыгып башкарыла:

- әгәр эш 100 яки аннан артыграк сүздән торса, грамоталылык 6 нчы таблица нигезендә бәяләнә;
- эшнең күләме 50-99 сүздән торса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый (югары күрсәтелгәнчә);
- әгәр эшнең күләме 50 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.
- бердәм республика тестын тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **35.**